**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 гыйнварындагы 95 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 июлендәге 2369 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесын, Чкалов һәм Степан Халтурин урамнарыннан алып М-7 “Волга” автомобиль юлына кадәрге участокны реконструкцияләү» линия объекты территориясен ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында**

«Беренчел документларны әзерләү үзәге» муниципаль унитар предприятиесе гаризасын карап тикшергәннән соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45 һәм 46 статьялары, 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдән чыгуын тану хакында»гы федераль законның 8 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 19 июлендәге 3035 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 июлендәге 2369 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесын, Чкалов һәм Степан Халтурин урамнарыннан алып М-7 “Волга” автомобиль юлына кадәрге участокны реконструкцияләү» линия объекты территориясен ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләр проектын әзерләү турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 17 июнендәге 1864 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәре Киров районында Горький шоссесын, Чкалов һәм Степан Халтурин урамнарыннан алып М-7 “Волга” автомобиль юлына кадәрге участокны реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру проекты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм

территорияне ызанлау проектлары, мондый территорияне планлаштыру проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырмыйча раслана торган очракларны билгеләү турында»гы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 июлендәге 2369 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 декабрендәге 4368 номерлы, 2023 елның 4 маендагы 1302 номерлы, 2023 елның 19 июнендәге 1698 номерлы, 2024 елның 31 гыйнварындагы 351 номерлы, 2025 елның 11 февралендәге 340 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесын, Чкалов һәм Степан Халтурин урамнарыннан алып М-7 “Волга” автомобиль юлына кадәрге участокны реконструкцияләү» линия объекты территориясен ызанлау проектына, аның аерым өлешләрен әлеге карарның кушымтасы нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 19 гыйнварындагы
95 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 июлендәге 2369 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесын, Чкалов һәм Степан Халтурин урамнарыннан алып М-7 “Волга” автомобиль юлына кадәрге участокны реконструкцияләү» линия объекты территориясен ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. «I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә» бүлегендә:

1.1. 2 «Ясала торган җир кишерлекләре исемлеге. Икенче этап» таблицасында «Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры» графасында «16:50:300108:386» номерын «16:50:300108:393» номерына алыштырырга.

1.2. 5 «Гомуми файдаланудагы территорияләргә кертеләчәк шәхси милектәге җир кишәрлекләренең мәйданы турында белешмәләр һәм аларның исемлеге. Беренче этап» таблицасында:

| Кадастр номеры | Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Мәҗбүри алу |
|---|---|---|---|
| «16:50:300108:386 | 153 | Гомуми мәйданы 400 кв.метрдан артмаган ваклап сату кибетләре (универсаль, махсуслаштырылган); «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль закон һәм мондый объектларны урнаштыру тәртибен җайга сала торган муниципаль хокукый актлар нигезендә урнаштырыла торган стационар булмаган сәүдә объектлары (код 4.4) | Тулысынча» |

юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| Кадастр номеры | Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Мәҗбүри алу |
|---|---|---|---|
| «16:50:300108:393 | 62 | Гомуми мәйданы 400 кв.метрдан артмаган ваклап сату кибетләре (универсаль, махсуслаштырылган); «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль закон һәм мондый объектларны урнаштыру тәртибен җайга сала торган муниципаль хокукый актлар нигезендә урнаштырыла торган стационар булмаган сәүдә объектлары (код 4.4) | Тулысынча» |

______________